РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» август 2023 ел г. Альметьевск № 2763

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Әлмәт муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы балаларны ике тапкыр бушлай туклandыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 02 июнендәге 780 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 28 июнендәге 02-08/288 номерлы протестын карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Әлмәт муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы балаларны ике тапкыр бушлай туклandыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 02 июнендәге 780 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

4.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә оештырылган сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга ике тапкыр түләүсез туклану ике мәртәбә түләүсез туклануны алыштыру турында гариза нигезендә уку көннәре өчен акчалата компенсация белән алмаштырыла. (Тәртипкә 2 нче кушымта).

Уку елы башыннан белем бирү учреждениесенә укырга кабул ителгән яки уку елы башыннан акчалата компенсация алу хокукы алган сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга акчалата компенсация уку елының 1 сентябреннән бирелә.

Зак. № 305-2000

Уку елы дәвамында белем бирү учреждениесенә укырга кабул ителгән яки уку елы дәвамында акчалата компенсация алу хокукы алган сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга акчалата компенсация түләү ай саен бирелә, акчалата компенсация турында гариза биргән айдан соң килүче айның 1 числосыннан бирелә.».

4.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Акчалата компенсация күләме уку көнендә һәм шушы максатларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә түләүсез ике тапкыр туклану бирү бәясеннән чыгып билгеләнә.

Белем бирү учреждениесе боерыгы нигезендә акчалата компенсация ай саен, акчалата компенсация турында гаризада күрсәтелгән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучы яисә аның ата-анасы (законлы вәкиле) исәбеннән, киләсе айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, белем бирү учреждениесе тарафыннан күчерелә.».

түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта өстәргә:

«Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми
белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы
Әлмәт муниципаль районы муниципаль гомуми
белем бирү учреждениеләрендә белем алучы,
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы
балаларны ике тапкыр бушлай тукландыруны
оештыру тәртибенә 2 нче кушымта

Гомуми белем бирү мәктәбе директорына
№________
Ф.И.О. ____________________________
Ф.И.О.____________________________
адресы буенча яшәүче:
___________________________________
___________________________________
Паспорт сериясе_____№________
Бирү датасы __________________
Кем тарафыннан бирелгән______
______________________________

ГАРИЗА

____дән ______га кадәр белем бирү учреждениесе тарафыннан өйдә белем бирү оештырыла торган 3 нче сыйныф укучысы

_____________________________________________________________________
(Укучының Ф.И.О.)

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7, 7.1,7.2 өлеше нигезендә ике тапкыр бушлай ашатуны /акчалата компенсацияне (кирәклесен ассызыкларга) бирүегезне сорыйм.

_______________ _______________
(дата) (имза)

Гаризага теркәлә:

- психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсе;

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документның күчермәсе;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;
- банк реквизитлары күчермәсе (белем алучы/законлы вәкил).».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов